ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ
АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

# ҺӨНӘРИ БЕЛЕМ БИРҮ УКУ ЙОРТЛАРЫНЫҢ РУС ТЕЛЛЕ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН ҮРНӘК ЭШ ПРОГРАММАСЫ

# “ТАТАР ТЕЛЕ” ҺӘМ “ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ” ПРЕДМЕТЛАРЫ БУЕНЧА

КАЗАН
2017

ББК 74.268.1Тат+74.268.3
һ 73

ТРМҮИ ректоры Р.Р. Бәдриеваның гомуми редакциялегендә

“Татар теле һәм әдәбияты” предметының эш программасы дәүләт стандартының федераль компоненты һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) татар телен һәм әдәбиятын укыту программасына нигезләнеп эшләнде

**Төзүче авторлар:**

1. Галәветдинова Люция Рәхимҗан кызы,Түбән Кама педагогия көллиятенең фәнни-методик эшләр буенча директор урынбасары, югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы.
2. Дәүләтшина Гөлчәчәк Барис кызы, Е.Н. Батенчук исемендәге Кама төзелеш көллиятенең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы.
3. Кәрамова Альбина Җәүдәт кызы, Яр Чаллы педагогия көллиятенең беренче квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы.
4. Мулланурова Гөлфизә Мидхәт кызы, Казан технология һәм дизайн көллиятенең югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы.
5. Нигъмәтҗанова Фәния Мәсгут кызы, Татарстан Республикасы урта һөнәри белем бирү уку йортларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының методик берләшмәсе җитәкчесе, Казан сәүдә-икътисад техникумының югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы.
6. Урманчева Люфия Зөфәр кызы, Түбән Кама нефть химиясе һәм нефть эшкәртү техникумының югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

**Фәнни җитәкче:** Шәмсетдинова Рәсимә Равиловна, ТР Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире филол.фәннәре канд., доцент, РФ Югары мәктәбенең атказанган хезмәткәре.
**Рецензентлар:** Хадиева Гөлнара Василовна, ТР Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасының өлкән укытучысы;
Мөхәрләмова Гөлназ Нурфатовна, Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият, тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре, филол. фәннәре канд., доцент.

**© ТРМҮИ, 2017**

**ЭЧТӘЛЕК**

АҢЛАТМА ЯЗУЫ ..........................................................................................

УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНА ГОМУМИ АҢЛАТМА...........................................

УКУ ПЛАНЫНДА ФӘННЕҢ ТОТКАН УРЫНЫ ..........................................

УКУ-УКЫТУ ПРЕДМЕТЫН ҮЗЛӘШТЕРҮ ПРОЦЕССЫНДА ШӘХСИ, МЕТАПРЕДМЕТ, ПРЕДМЕТ НӘТИҖӘЛӘРЕ ..............................................

УКУ ПРЕДМЕТЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ ...............................................................

УКУ-УКЫТУ ЭШЧӘНЛЕГЕН ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ......................

УКЫТУНЫҢ МАТДИ-ТЕХНИК ҺӘМ МӘГЪЛҮМАТИ ЯКТАН ТӘЭМИН ИТЕЛЕШЕ ..........................................................................

# АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Федераль Дәүләт стандартларында белем бирү системасының төп үсеш юнәлеше – **системалы-эшчәнлекле юнәлеш,** ә системаны барлыкка китерә торган төп компонент – **нәтиҗә: шәхси, метапредмет, предмет нәтиҗәләре** дип билгеләнелә. Стандартларда күрсәтелгән бу концептуаль методологик нигез барлык фәннәрне укыту системасына да, шул исәптән рус телле укучыларга татар телен һәм татар әдәбиятын укыту системасына да карый. Ягъни рус телле укучыларга татар теле һәм татар әдәбияты укыту системасының барлык **компонентлары** да: программалар, укыту-методик комплектлары, дәрес процессы, контроль, идарә итү, белем күтәрү һ.б. – бар да бер максатка – **нәтиҗәгә** хезмәт итә.

Билгеле булганча, укытуның максаты җәмгыять тарафыннан куелган социаль заказ белән билгеләнә. Татарстан Республикасында белем бирү системасының төп бурычы – иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле, ике дәүләт һәм чит телләрдә дә иркен сөйләшеп аралашучы билингваль (полилингваль) шәхес тәрбияләү.

Татарстан Республикасы Конституциясенең 8 нче маддәсендә һәм “Татарстан Республикасы халыкларының телләре турындагы” Законда күрсәтелгәнчә, Татарстанда дәүләт телләренең икесен дә белү халыкларның үзара аңлашып, тату яшәвенең нигезен тәшкил итә. Татар теле, дәүләт теле буларак, барлык урта һөнәри уку йортларында төп уку предметларының берсе булып тора.

Әлеге программа рус телле укучыларга татар теле һәм әдәбият укыту буенча эш программаларын төзү өчен нигез булып тора: ул укыту предметының мәҗбүри өлешен билгели. Эш программаларына, уку йортының эш үзенчәлеген, укучыларның индивидуаль мөмкинлекләрен исәпкә алып, уку материалын өйрәнүгә сәгатьләр саны бүленешен һәм материалны өйрәнү эзлеклелеген билгеләүдә, эчтәлекне киңәйтүдә, шулай ук укучыларның коммуникатив компетенцияләрен формалаштыру юлларын ачыклауда укытучылар үзгәрешләр кертә алалар. Бу үзгәрешләр эш программаларының аңлатма язуында чагылыш табарга тиеш.

Программа дәүләт контроле һәм белем сыйфатын билгеләү системасы өчен нигез булып тора.

# УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНА ГОМУМИ АҢЛАТМА

Татар теле һәм әдәбиятын укыту максатлары берничә аспектны үз эченә ала: танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү.

**Танып белү максатының эчтәлеге**

Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш, шушы төбәктә төп халык булып саналган татар халкы мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тарихи үткәнен, бүгенгесен, киләчәген белү зарур. Татар халкы белән кулга-кул тотынып яшәргә әзерләнүче һәр кеше бу халыкның бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзенең рухи үсешен баета алу мөмкинлегеннән файдаланырга тиеш. Программа эчтәлеге телгә өйрәтү процессын бала өчен “башка дөньяга тәрәзә ачу” булырлык һәм шуның аркылы аның үз яшәешен дә тулырак аңлавына ярдәм итәрлек итеп сайланды.

Һөнәри уку йортларында татар халкының рухи дөньясын чагылдырган, тормыш-көнкүрештәге әхләкый проблемаларны үз эченә алган, укучыларның кызыксынуларына, яшь үзенчәлекләренә туры килгән әдәби әсәрләр белән танышу; Татарстанда яшәүче милләтләр, Татарстанның дәүләт символлары, Татарстанның территориясе, географик урыны; башкалабыз Казанның тарихи үткәне, бүгенге йөзе; татар сәнгатенең төрле тармаклары буенча күренекле шәхесләр турында укучыларның татарча сөйли алулары төп максат итеп куела.

**Үстерү максатының эчтәлеге**

Шәхеснең белемле булуы, тәрбиялелек һәм аның фикерләү сәләте үсеше дәрәҗәсеннән дә тора. Укыту процессында үстерү, тәрбия максатларын даими күзаллап эшләү – укытуның практик ягы уңышлылыгының алшарты. Укучыларның психик үсешен түбәндәге юнәлешләрдә үстерүгә аеруча игътибар бирү таләп ителә:

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерләү;

– хәтерне үстерү (ихтыярый, ихтыярсыз), игътибарлылыкны үстерү;

– аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);

– ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне устерү.

Программага сайланган эчтәлек нигезендә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча да эш оештырганда, бу максатлар беренче планга куела.

**Тәрбияви максатның эчтәлеге**

Укучыларның тиешле дәрәҗәдәге тәрбиялелегеннән башка укыту процессын оештыру мөмкин түгел. Тәрбия процессы, беренче чиратта, укытуның эчтәлеге һәм методлары белән бәйле. Шуңа күрә программа эчтәлеген сайлаганда, материалның тәрбияви мөмкинлекләрен исәпкә алу мөһим. Эчтәлектә әхлакый проблемалар булган текстлар үзләре үк

коммуникатив мотивациягә ия, шунлыктан аралашу ситуациясе булдыру әллә ни кыенлык тудырмый. Башка милләт вәкилләренең күңелен яулардай, аларда гомумкешелек әхлакый сыйфатларны тәрбияләрдәй татар әдәбияты өлгеләре белән таныштыру да шушы ук максатка буйсындырыла, сөйләшү-аралашуга алып чыгуга кулайрак булган әдәби әсәрләр тәкъдим ителә.

**Белем бирү максатының эчтәлеге**

Укучыларның татар теле буенча лексик, грамматик күнекмәләре филологик белемнәр суммасы дәрәҗәсендә генә калмыйча, ә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә аралашуда кулланырлык дәрәҗәгә җитүе зарур. Ягъни, укучылар, нинди дә булса сүзне, я грамматик категорияне тану, аеру, аңлау, тәрҗемә итү дәрәҗәсендә генә түгел, аларны аралашу максатыннан мөстәкыйль кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиешләр. Шул вакытта гына татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү бурычы үтәлә.

Укучыларда татар әдәбияты текстларын рус әдәбияты әсәрләре белән гомумкешелек кыйммәтләренә мөнәсәбәттә чагыштыру күнекмәләре формалаштыруга, татар әдәбиятына хас рухи-әхлакый кыйммәтләрне, әдәби-эстетик үзенчәлекләрне аңларга өйрәтүгә, татар әдәбияты әсәрләрен аңлап укый һәм кабул итә алуга ирешү зарур.

Программага сайланган эчтәлек гомуми белем бирү системасының фундаменталь нигезен тәэмин итә һәм һөнәри урта белем бирү баскычында ул тирәнәйтелә. Шулай ук сайланган эчтәлек укучыны рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләү, укуның универсаль гамәлләрен формалаштыру максатларына хезмәт итә; урта гомуми белем бирү баскычы программасы белән дәвамчанлыкны саклый.

Укыту предметының эчтәлеге түбәндәге компетенцияләрне формалаштыруга юнәлдерелгән:

***Коммуникатив компетенция*** җирлегендә сөйләм эшчәнлегенең төрләре камилләштерелә. Укучы аралашу ситуацияләренә бәйле тел һәм сөйләм берәмлекләрен дөрес, төгәл сайлап, иркен куллана, үз фикерен раслый һәм дәлилли. Төрле стиль һәм жанрга караган текстлар төзи һ.б.

***Лингвистик компетенция*** татар теленең тармаклары буенча үзләштерергә тиешле төп теоретик мәгълүматлар керә:

1. “Сөйләм ситуациясе”, “әдәби тел”, “тел нормасы”, “сөйләм культурасы” төшенчәләре. Татар халкының язу тарихы, орфографик принциплар, орфоэпия. Татар теленең фонетик, график, орфографик, орфоэпик нормалары.

2. Лексикология фәненең тармаклары. Сүзнең лексик мәгънәсе, аның үсеш-үзгәреше. Татар теленең сүзлек составын төркемләү. Фразеологик әйтелмәләр, аларның лексик мәгънәсе. Төрле типтагы сүзлекләр. Телнең лексик нормалары.

3. Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы, татар теленең сүзлек составын баетуда сүз ясалышының роле.

4. Сүз төркемнәре, аларны төркемләү, сүз төркемнәренең үзара мөнәсәбәте. Телнең морфологик нормалары.

5. Синтаксисның төп берәмлекләре, аларның төрләре. Текст һәм аның берәмлекләренең үзара бәйләнеше. Телнең синтаксик нормалары.

6. Язма һәм сөйләмә тел, аларга хас үзенчәлекләр. Тел-сурәтләү чаралары, аларның төрләре. Татар сөйләменең сәнгатьлелеге.

***Этномәдәни компетенция*** җирлегендә телнең мәдәнияттән һәм тарихтан аерылгысыз булуына игътибарны юнәлтү. Тел берәмлекләрендә, аларның мәгънәләрендә миллилек чагылышын күрә белү, төрле телләрдә уртак төшенчәләрнең һәм берәмлекләрнең кулланылыш үзенчәлеген, алар аша дөньяны танып белүдәге уртак һәм аермалы якларны ачу; тел берәмлекләре аша милли дөнья картинасы ачылу үзенчәлекләрен өйрәтү (мәкаль-әйтемнәр, фразеологик берәмлекләр, ономастик лексика, афоризмнар). Татар сөйләм әдәбе нормалары өйрәтү һ.б.

Укучыларның сөйләм эшчәнлеге үсеше һәм шәхси үсеш-үзгәреше югарыда саналган компетенцияләрдә ачык чагыла: коммуникатив компетенция төркемендә өйрәнелә торган тел материалы аралашу күнекмәләре булдыру максатын күздә тотып бирелә, лингвистик компетенция төркемендә аралашу өчен кирәкле тел материалының төзелеше, структурасы, эчтәлеге тәкъдим ителә, социомәдәни компетенция төркемендә тел материалы халыкның мәдәниятен һәм тарихын чагылдыра торган билге буларак бирелә.

**Фәнне үзләштерү нәтиҗәсендә укучы куллана белергә тиеш:**

- Сөйләмнең үз контролен гамәлгә ашыру: куелган коммуникатив бурычларның нәтиҗәлелеге күзлегеннән чыгып телдән һәм язма әйтелмәләрне бәяләргә;
- Тел берәмлекләрен дөреслеге, төгәллеге һәм урынлы кулланылышы ягыннан анализларга;
- Төрле функциональ стильдәге текстларга лингвистик анализ ясарга;

***Сөйләмдә һәм язуда***

- Иҗтимагый-мәдәни,эшлекле аралашу һәм төрле типтагы фәнни жанрларда телдән һәм язмача монологик һәм диалогик сөйләм булдырырга;
- Сөйләмдә хәзерге заман татар теленең төп орфоэпик, лексик, грамматик нормаларын кулланырга;
- Язмада хәзерге заман татар теленең орфографик һәм пунктуацион кагыйдәләрне үтәргә;
- Төрле өлкәдә һәм ситуациядә аралашуның сөйләм тәртибе нормаларын үтәргә;
- Телдән һәм язмача текстта төп информацион алымнарны кулланырга.

**Фәнне үзләштерү нәтиҗәсендә укучы белергә тиеш:**

- Рус һәм башка халыклар теленең тарихы, мәдәнияте белән бәйләнешен;
- Сөйләм культурасы, тел нормалары, әдәби тел, сөйләм һәм аның компонентлары төшенчәләренең мәгънәсен;

- Телнең төп берәмлекләрен, аның дәрәҗәсен, билгеләрен һәм үзара бәйләнешен;
- Хәзерге заман татар әдәби теленең орфоэпик, лексик, грамматик, орфографик һәм пунктуацион нормаларын.

**Укучы фәнне үзләштерү нәтиҗәсендә алган белемнәрен һәм күнекмәләрен практикада һәм көндәлек тормышта куллана белергә тиеш.**

- Татар телен халыкның рухи, әхлакый һәм мәдәни байлыгы икәнен аңлау;
- Иҗади сәләтләрен, мөстәкыйль эш күнекмәләрен үстерү;
- Сүзлек запасын арттыру; тел һәм сөйләм чараларын куллану өлкәсен киңәйтү;
- Коммуникацион сәләтне камилләштерү;
- Үз белемең күтәрү һәм дәүләтнең иҗтимагый, мәдәни һәм җитештерү тормышында актив катнашу.
- Татар әдәби теленең нормаларын исәпкә алып кирәкле темага( телдән дә, язмача да) бәйләнешле текст төзү;
- Диалогта, дисскуссиядә катнашу;
- Әдәби культура күренешләре белән мөстәкыйль танышу, һәм аларның эстетик әһәмиятен бәяләү;
- Әдәби әсәрләргә бәя бирү.

Рус телле укучыларга татар теле һәм әдәбиятын укыту, ана теле һәм әдәбиятын укыту белән беррәттән, аларның филологик белемнәрен киңәйтә һәм коммуникатив культурасын үстерә.

Татарстан Республикасы урта һөнәри белем бирү баскычында татар теле һәм әдәбияты предметын укытуга 117 сәгать билгеләнә. Шулай ук, базис укыту планында сәгатьләр саны бүленеше күрсәтелә, уку вакыты программаның вариатив өлеше булып тора һәм эш программасын төзүчеләр тарафыннан билгеләнелә.

| **Укыту төрләре** | ***Сәгатьләр саны*** |
|---|---|
| **Максималь эш күләме (барлыгы)** | *117* |
| **Мәҗбүри эш күләме (барлыгы)** | *78* |
| шул исәптән: | |
| Практик эшләр | *78* |
| Курс эше (проект) | |
| **Укучыларның мөстәкыйль эше( барлыгы)** | *39* |
| *Аттестация: 2 семестр - дифференциаль зачёт* | |

## УКУ-УКЫТУ ПЛАНЫНДАГЫ ПРЕДМЕТНЫҢ УРЫНЫ

Эш программасы урта һөнәри белем бирү төп программасының Федераль дәүләт белем бирү стандартына(ФДББС) туры китереп түбәндәге һөнәрләргә өйрәткәндә кулланыла: (һәр һөнәри уку йортының белгечлекләре санала)

Татар теле һәм әдәбияты фәненең төп һөнәри белем бирү программасы төзелешендәге урыны: гомумбелем бирү циклы.

Урта һөнәри уку йортларында татар теле һәм әдәбияты фәнен укыту концентрик юнәлештә оештырыла, ягъни мәктәптә укыту предметының эчтәлеге тирәнтен кабатлана, барлык үзләштерелгән материал сөйләм эшчәнлеге барышында кабатлана һәм ныгытыла.

## УКУ-УКЫТУ ПРЕДМЕТЫН ҮЗЛӘШТЕРҮ ПРОЦЕССЫНДА ШӘХСИ, МЕТАПРЕДМЕТ, ПРЕДМЕТ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Урта һөнәри уку йортларында телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теле һәм әдәбиятының күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу башка мәдәнияткә карата ихтирам хисе уята, ягъни укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә, аларда ватанпәрвәрлек хисе уята.

Урта һөнәри уку йортларында татар теле һәм әдәбиятын өйрәтүнең программада күрсәтелгән күләмдә гомуми нәтиҗәләре:

- укучыларның коммуникатив компетенциясен (аралашу осталыгын) үстерү, ягъни татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашу күнекмәләре булдыру;
- коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә аралашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, итагатьле һәм киң күңелле әңгәмәдәш булу;
- “Татар теле һәм әдәбияты” предметына карата уңай мотивация, тотрыклы кызыксыну булдыру һәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татар теле һәм әдәбиятын уңышлы үзләштерүгә шартлар тудыру.

Урта һөнәри уку йортларын тәгәлләгәндә, укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге **шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана**:

- шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теле һәм әдәбиятына карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;
- әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
- әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;
- “гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”, төшенчәләрен кабул итү, “башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык”, “кеше кадерен белү” кебек хисләр формалашу.

Урта һөнәри уку йортларында татар теле һәм әдәбиятын укытуның **метапредмет нәтиҗәләре.** Татар теле һәм әдәбияты, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган укуның универсаль гамәлләрен (***танып белү, регулятив, коммуникатив)*** формалаштыруга хезмәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар текст, күрмә-график рәсемнәр, хәрәкәтле яисә хәрәкәтсез сурәтләр, ягъни төрле коммуникацион технологияләр аша

тапшырыла торган мәгълүмати объектлар белән эшләү тәҗрибәсе ала; презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәнә; укучыларда, компьютер яисә ИКТ нең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алу күнекмәләре формалаша.

***Танып белү нәтиҗәләре:***

- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
- иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру;
- объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
- төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
- тиешле мәгълүматны табу өчен, энциклопедия, белешмәләр, сүзлекләр, электрон ресурслар куллану.

**Регулятив нәтиҗәләр:**

- уку хезмәтендә үзенә максат куя, бурычларны билгели белү;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
- уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;
- билгеләгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;
- дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли һәм алар белән дөрес эш итә белү;
- дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү.

**Коммуникатив нәтиҗәләр:**

- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
- әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
- аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);
- парларда һәм күмәк эшли белү;
- мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
- әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

**Сөйләм эшчәнлегенең төрләре буенча күнекмәләр**

***Сөйләү***

- аралашканда, төрле репликалардан (сораштыру, кабатлап сорау, тәкъдим итү, риза булу һ.б.) урынлы файдалану;
- әңгәмәдәшнең социаль хәлен исәпкә алып, сөйләшү оештыру;

– аралашу барышында фикерне төгәл җиткерү;
– киңәйтелгән репликалар кулланып, сөйләшү үткәрү;
– укылган текстларның эчтәлеге буенча бәхәсләрдә катнашу, үз карашларыңны раслау һәм дәлилләү;
– укылган әдәби әсәрләрнең эчтәлеге буенча әңгәмә кору.
– төрле җөмлә калыпларын урынлы кулланып, дөнья яңалыклары турында хәбәр итү һәм аларга карата үз мөнәсәбәтеңнебелдерү;
– татар классик әдипләренең тормышы һәм иҗаты турында сөйләү;
– тәкъдим ителгән ситуация буенча сөйләшү үткәрү (һәр укучының репликалар саны 12дән ким булмаска тиеш).
– сөйләм нормаларына нигезләнеп, эзлекле һәм аңлаешлы, грамматик яктан дөрес сөйләм булдыру (җөмләләр саны 14тән ким булмаска тиеш);
– укылган (тыңланган) текстның эчтәлеген аңлап, авторның позициясен аңлату һәм анда күтәрелгән мәсьәләләргә карата үз мөнәсәбәтеңне белдерү.

***Тыңлап аңлау***

– 2 минутлык текстны тыңлап, аның төп эчтәлеге турында үз фикерләреңне белдерү;
– җанлы сөйләмне тыңлап аңлап, күмәк сөйләшүдә катнашу;
– тыңланган мәгълүматны аңлатып бирү;
– лексик темаларга караган яңалыкларны тыңлап аңлау һәм аларның эчтәлеген башкаларга җиткерү.

***Уку***

– уку төрләреннән файдаланып, тексттан кирәкле мәгълүматны табу һәм аның эчтәлеген телдән яки язмача белдерү;
– текст белән мөстәкыйль эшләү күнекмәләренә ия булу;
– шигъри текстларны яттан сөйләү;
– татар һәм рус телләрендәге әдәби әсәрләрнең уртак һәм милли үзенчәлекләрен билгеләү, әхлакый кыйммәтләрне чагыштырып бәяләү.

**Язу**

– аралашу ситуациясенә карата фикерләрне язмача белдерү;
– сөйләм ситуацияләренә бәйле репликаларны татарча яза белү;
– өйрәнелгән темага яки укылган текстның эчтәлегенә нигезләнеп, сочинение язу;
– төрле чыганаклардан файдаланып, тәкъдим ителгән темага реферат язу.

**Тел чаралары һәм аларны куллану күнекмәләре**

***Сөйләмнең фонетик ягы***

– татар сөйләмен фонетик яктан дөрес оештыру;
– лексик темаларга караган сүзләрдә басымны дөрес кую;
– кушма, тезмә, парлы һәм кыскартылма сүзләрне дөрес әйтү;
– сөйләмдә иҗек чигендәге фонетик үзгәрешләрне истә тоту: *күк — күге, кунак — кунагы, тап — таба, тек әле — тегәле;*

- хикәя, сорау, боеру һәм тойгылы җөмләләрне дөрес интонация белән әйтү.

***Сөйләмнең лексик ягы***

- актив үзләштерелгән лексик берәмлекләрне, шул исәптән кушма, тезмә, парлы һәм кыскартылма сүзләрне дөрес куллану;
- антоним, синоним, омонимнарны сөйләмдә урынлы куллану;
- лексик берәмлекләрнең күчерелмә мәгънәләрен, башка сүзләр белән бәйләнешкә керү үзенчәлекләрен белү.

***Сөйләмнең грамматик ягы***

- өйрәнелгән грамматик формаларны сөйләмдә дөрес куллану һәм тексттан табып әйтү;
- тезмә кушма һәм иярченле кушма җөмләләрне кулланып, бәйләнешле текст төзү.

**Социаль-мәдәни күнекмәләр**

Татарстан Республикасының халыкара мөнәсәбәтләре, китапханәләре, тарихи һәм истәлекле урыннары, татар халкының күренекле шәхесләре, милли традицияләре турында мәгълүматлы булу.

**Махсус күнекмәләр**

Ике телле, антонимнар, синонимнар, фразеологик һәм башка төр сүзлекләрдән, белешмә материаллардан, мультимедиа әсбапларыннан, татар сайтларыннан файдалану; сүзлекчә алып бару.

## УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

**Сөйләмнең предмет эчтәлеге**

Телдән һәм язма сөйләмнең эчтәлеге белем һәм тәрбия бирү максатларыннан, шулай ук укучыларының яшь үзенчәлекләре һәм мәнфәгатьләреннән чыгып билгеләнә.

*Телләр белгән – илләр белгән. Икетеллелек – дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләре. (6 сәгать).*

*Кеше һәм мохит. Иҗтимагый урыннар. Ашханәдә. Кибеттә. Шәһәрдә. Юлда, сәфәрдә. Авылда (20 сәгать).*

*Туган ягыбызның табигате. Татарстан табигате, климаты. Ел фасыллары (6 сәгать).*

*Туганлык мөнәсәбәтләре. Гаилә. Аралашу культурасы (6 сәгать).*

*Тарихка сәяхәт. Болгар һәм Зөя утрау- шәһәрчеге (4 сәгать).*

*Татарстан Республикасы. Дәүләт символлары (6 сәгать).*

*Чит илләрдәге татарлар. Яшәеше, гореф-гадәтләрнең сакланышы (4 сәгать).*

*Казан- Татарстанның башкаласы. Туган төбәкнең тарихи һәм истәлекле урыннары (6 сәгать).*

*Китапханәләр. Казандагы милли китапханә (4 сәгать).*

*Татарстан музейлары. Милли музейлар. Күргәзмәләр. (4 сәгать).*

*Татар әдипләре (10 сәгать, укытучы карамагына). Татар әдәбияты буенча якынча исемлек:*

1. Ф. Әмирхан. “Хәят”.
2. К.Тинчурин “Сүнгән йолдызлар”.
3. Г. Камал. “Беренче театр”.
4. М. Җәлил. “Җырларым”, “Кичер, илем”.
5. Ә. Еники. “Кем җырлады?”.
6. Ф. Кәрим “Үлем турында уйлама”.
7. Г. Кутуй. “Тапшырылмаган хатлар”.
8. Г. Әпсәләмов. “Ак чәчәкләр”.
9. Х. Туфан. “Кайсыгызның кулы җылы?”.
10. И. Юзеев. “Мин телим дусларга”.
11. Ф. Яруллин. “Сез иң гүзәл кеше икәнсез”.
12. Т. Миңнуллин. “Әлдермештән Әлмәндәр”, “Илгизәр+ Вера”.
13. Р. Миңнуллин. “Ә ни өчен?”.
14. Р. Фәйзуллин. “Алтын балык түгел, гади балык сөйләде”.
15. Р. Байтимеров. Татарстан гимны.

**Тел материалы**

*Фонетика*. Лексик темаларга караган сүзләрнең әйтелеше һәм язылышы. Әйтелеше белән язылышы арасында аерма булган сүзләр. Сүз һәм фраза басымы.

*Лексика.* Аралашу темаларына караган лексик берәмлекләрне рецептив һәм продуктив рәвештә үзләштерү. Тотрыклы сөйләм

гыйбарәләре; сөйләм әдәбе берәмлекләре. Актив үзләштерелгән сүзләрнең синонимнары, антонимнары. Фразеологик берәмлекләр. Күп мәгънәле сүзләр.

*Грамматика.* Аерым сүз төркемнәренә хас грамматик формаларның татар һәм рус телләрендә тәңгәл килү-килмәве: татар телендә исемнең род категориясе булмавы һәм аның лексик берәмлекләр белән бирелеше; татар телендә исемнең тартым категориясе булуы һәм аның рус телендә бирелеше; татар телендә хикәя фигыльнең заман формаларына хас мәгънәви үзенчәлекләр; татар телендә фигыльнең вид категориясе булмавы һәм аның аналитик формалар белән бирелеше; татар телендә сыйфатның сыйфатланмыш белән ярашмавы; бәйлек һәм бәйлек сүзләрнең татар телендә сүздән соң килүе; татар сөйләмендә кисәкчәләрнең препозитив *(иң,үтә, тома, шыр, әллә)* һәм постпозитив (*түгел, бит, инде, әле,гына/генә, кына/кенә, ук/үк)* булуы; татар телендә саннарның һәм сыйфатларның исем янында төрләнмәве (*өч малайда- у трех мальчиков; бишенче сыйныфта — в пятом классе; җиде баланың — у семи детей, матур бинада — в красивом здании);* микъдар саны белән янәшә килгәндә, исемнәрнең сан белән төрләнмәве; затланышлы һәм затланышсыз фигыльләрнең үзенчәлекләре.

Җөмләдә сүз тәртибе. Җөмләдә сүзләрне бәйләүче чаралар. Татар телендәге хикәя җөмләнең хәбәр белән тәмамлану үзенчәлеге. Татар җөмләсендә сөйләм яңалыгының хәбәр алдында урнашуы. *(Бүген безгә* ***кунаклар*** *килә. Кунаклар безгә* ***бүген*** *килә. Кунаклар бүген* ***безгә*** *килә).* Кушма җөмлә турында гомуми төшенчә.

# УКУ-УКЫТУ ЭШЧӘНЛЕГЕН ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

| Бүлекләр һәм темалар | Сәгатьләр саны |
|---|---|
| ***Телләр белгән – илләр белгән.*** *Икетеллелек – дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләре.*<br>*Фонетика*. Лексик темаларга караган сүзләрнең әйтелеше һәм язылышы. Әйтелеше белән язылышы арасында аерма булган сүзләр. Сүз һәм фраза басымы. | **6** |
| ***Кеше һәм мохит.*** *Иҗтимагый урыннар. Ашханәдә. Кибеттә. Шәһәрдә. Юлда, сәфәрдә. Авылда*.<br>***Лексика***.Аралашу темаларына караган лексик берәмлекләрне рецептив һәм продуктив рәвештә үзләштерү. | **20** |
| ***Туган ягыбызның табигате****. Татарстан табигате, климаты. Ел фасыллары*. **Лексика**.Тотрыклы сөйләм гыйбарәләре; сөйләм әдәбе берәмлекләре. Актив үзләштерелгән сүзләрнең синонимнары, антонимнары. Фразеологик берәмлекләр. Күп мәгънәле сүзләр. | **6** |
| ***Туганлык мөнәсәбәтләре****. Гаилә. Аралашу культурасы.*<br>**Исем.** Татар телендә исемнең род категориясе булмавы һәм аның лексик берәмлекләр белән бирелеше; татар телендә исемнең тартым категориясе булуы һәм аның рус телендә бирелеше. | **6** |
| ***Тарихка сәяхәт.*** *Болгар һәм Зөя утрау-шәһәрчеге*<br>**Фигыль**. Затланышлы һәм затланышсыз фигыльләрнең үзенчәлекләре. Хикәя фигыльнең заман формаларына хас мәгънәви үзенчәлекләр. | **4** |
| ***Татарстан Республикасы.*** *Дәүләт символлары. Республиканың казанышлары.*<br>**Фигыль**. Татар телендә фигыльнең вид категориясе булмавы һәм аның аналитик формалар белән бирелеше. | **6** |
| ***Чит илләрдәге татарлар.*** *Читтә яшәүче татарларның яшәеше, гореф-гадәтләрнең сакланышы*.<br>**Сыйфат.** Татар телендә сыйфатның сыйфатланмыш белән ярашмавы.<br>**Рәвеш.** | **4** |
| ***Казан – Татарстанның башкаласы.*** *Туган төбәкнең тарихи һәм истәлекле урыннары.*<br>**Сан.** Татар телендә саннарның һәм сыйфатларның исем янында төрләнмәве. | **6** |
| ***Китапханәләр.*** *Татарстан Республикасының милли китапханәсе.*<br>**Бәйлек һәм бәйлек сүзләр**нең татар телендә сүздән соң килүе. | **4** |

| | |
|---|---|
| ***Татарстан музейлары**. Милли музейлар. Күргәзмәләр.* **Кисәкчәләр**.Татар сөйләмендә кисәкчәләрнең препозитив һәм постпозитив булуы. | **4** |
| ***Татар әдипләре.*** ***Синтаксис.*** Җөмләдә сүз тәртибе. Җөмләдә сүзләрне бәйләүче чаралар. Татар телендәге хикәя җөмләнең хәбәр белән тәмамлану үзенчәлеге. Татар җөмләсендә сөйләм яңалыгының хәбәр алдында урнашуы. Кушма җөмләләр. | **10** |
| ***Дифференциаль зачет*** | **2** |
| ***Мәҗбүри сәгатьләр саны*** | **78** |
| ***Аудиториядән тыш мөстәкыйль эш*** | **39** |
| ***Барлыгы*** | **117** |

# УКЫТУ-ТӘРБИЯ ПРОЦЕССЫН УКУ-УКЫТУ, МЕТОДИК ӘСБАПЛАР ҺӘМ МАТЕРИАЛЬ-ТЕХНИК ЧАРАЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТЕЛЕШЕ

Укыту фәнен гамәлгә ашыру түбәндәгеләрне таләп итә:

- Татар теле һәм әдәбияты кабинетының булуы;

Кабинетны җиһазлау:

- укучылар саны исәбеннән эш урыннары;
- укытучының эш урыны;
- такта;
- татар теле һәм әдәбияты фәннәре буенча укыту - методик комплект;
- татар теле һәм әдәбияты фәннәре буенча укыту - күрсәтмә әсбаплар;
- укучыларның мөстәкыйль эшен оештыру буенча методик рекомендацияләр;
- практик эшләргә методик рекомендацияләр;
- дәреслекләр;
- сүзлекләр;
- эш дәфтәрләре;
- программалар, тематик һәм дәрес планнары;
- күрсәтмә материал;
- татар теле һәм әдәбиятыннан төрле дәрәҗәдәге дидактик материал;
- тестлар;
- фонетика, морфология, сүз ясалышы буенча тематик папкалар;
- методик китапханә (китаплар, газета һәм журналлар)
- иҗади эшләр өчен материал;
- тематик стендлар.

Татар теленә һәм әдәбиятына өйрәткәндә, түбәндәге материаль-техник чаралардан файдалану таләп ителә: аудио һәм видео әсбаплар; мультимедиа укыту программалары; электрон дәреслекләр; компьютер программалары; интерактив программалар; электрон китапханә; татар сайтлары (**belem.ru; tatarile.org.com);** “АНА ТЕЛЕ” онлайн-мәктәбе (anatele.ef.com).

**Информацион тәэмин ителеш**

**а) төп әдәбият:**


1. Сафиуллина Ф.С., Ибраһимов Г.Б. Хикмәтле дә, бизәкле дә тел. – Казан: Мәгариф, 2013. – 176
2. Татарча сөйләшик = Давайте говорить по-татарски = Let's speak tatar: уку әсбабы/ К.С. Фәтхуллова, Ә.Ш. Юсупова, Э.Н. Денмөхәммәтова; [Д.Р. Шәрифуллина тәрҗ.]. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2012. – 311 б.
3. Татар әдәбияты = Татарская литература: Учебник-хрестоматия для студентов сред. спец. учеб. заведений/ Авт.-сост.: А.Г. Махмудов, Н.Г. Гараева, Л.Ю. Мухаметзянова, – Казань: Магариф, 2010. – 631с.
4. Харисова, Ч.М. Татарский язык: справочник/ Ч.М. Харисова. – Казань: Татар. Кн. Изд-во, 2014. – 191 с.

5. Шаяхметова, Л.Х. Татарский язык для начинающих: интенсивный курс. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. – 223 с.

**б) өстәмә әдәбият:**

1. Федеральный закон от 29.12.2012 N 273-ФЗ (ред. от 30.12.2015) "Об образовании в Российской Федерации".
2. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы (2004 ел, 1 июль).
3. Татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты. – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы. – Казан, 2008.
4. Татар теле һәм әдәбият укытучысына ярдәмгә: ФДББС турында белешмәлек һәм терәк схемалар: методик ярдәмлек / төзүчеләр: А.Х. Мөхәммәтҗанова, Р.Б. Камаева, – Казан: ТРМҮИ, 2015. – 68.
5. ФГОС СПО.
6. Абдуллина Р.С., Шайхиева Г.М.Татарский язык. Учебное пособие для 10 класса (для учащихся-татар).– Казань: Татар. кн. изд-во., 2012. – 212с.www.tatkniga.ru
7. Асадуллин А.Ш., Юсупов Р.А. Татарский язык в русскоязычной аудитории. – Казань: Мәгариф, 1995. – 206 с.
8. Литвинов И.Л. Я начинаю говорить по-татарски. Учебное пособие. – Казань: изд-во «ГранДан», 1998. – 278 с.
9. Нигматуллина Р.Р. Методическое пособие (Сборник упражнений и текстов по татарскому языку для русскоязычных учащихся) (на татар.яз) – Набережные Челны. 2001.
10. Сафиуллина Ф.С., Ибраһимов С.М. Татарский язык. Учебное пособие для 11 класса (для учащихся-татар) [отв. за изд. Ч.М.Харисова]. – Казань: Татар. кн. изд-во., 2012. – 247 с.www.tatkniga.ru
11. Сафиуллина Ф.С. Татарский язык (интенсивный курс). – Казань: изд-во «Хәтер», 1998. Сафиуллина Ф.С., В.З. Гарифуллин. Татарский язык. Учебник для 9 класса русской средней общеобразовательной школы. – Казань: Магариф, 1998.- 159с.
12. Сборник правил по татарскому языку для русскоязычных учащихся. Казань, Издательство “Гыйлем”, 2008.
13. Тел – акылның баскычы. Татар теле дәресләре: Урта махсус уку йортлары өчен дәреслек/ М.С. Артюшина, Р.Р. Мәүлетшина, Ф.М. Нигъмәтҗанова, Р.Н. Хөсәенова. – Казан: Мәгариф, 2007. – 159 б.

**в) интернет-ресурслар:**

http://belem.ru
http://suzlek.ru
http://kitap.net.ru
http://gabdullatukay.ru/
http://www.tugan-tel.com/
http://www.tatknigafund.ru/

ҺӨНӘРИ БЕЛЕМ БИРҮ УКУ ЙОРТЛАРЫНЫҢ
РУС ТЕЛЛЕ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ҮРНӘК ЭШ ПРОГРАММАСЫ

“ТАТАР ТЕЛЕ” ҺӘМ “ӘДӘБИЯТ”
ПРЕДМЕТЛАРЫ БУЕНЧА

Форм.бум. 60х84 $^{1}/8$. Гарнитура Таймс
Усл.печ.л. 2,4
Оригинал-макет подготовлен
в редакционно-издательском отделе
Института развития образования Республики Татарстан
420015 Казань, Б.Красная, 68
Тел.:(843)236-65-63 тел./факс (843)236-62-42
E-mail: irort2011@gmail.com